СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д. 3, с. Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**

**Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы**

**карары**

**« 30 » октябрь 2023 ел** **№6**

**Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Чиканас авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставының 25 маддәсе нигезендә, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Чиканас авылы, Совет урамы, 31йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 16 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Чиканас авылы, Совет урамы, 31йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 16 ноябренә 16 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Совет урамының 1 йортыннан 58 йортына кадәр яшәүчеләр.

2нче этап: Совет урамының 59 йортыннан 74 йортына кадәр, Октябрь урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

« Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Чиканас авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә түләү күләме 500 сум тәшкил итә, көндезге формада укучы студентларга, 80 яшьтән узган гражданнарга 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-

аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

- Октябрь урамының 1 йортыннан зиратка кадәр юлга нигез салу һәм вак таш җәю -200м?

«ӘЙЕ» « КАРШЫ»»

5. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Чиканас авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына Татарстан Республикасы, Арча районы, Чиканас авылы, Совет урамы, 31 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7 . Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

СОВЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ